| | |
|---|---|
| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.12.2025 Баулы шәһәре № 17

Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 996 номерлы карары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 90 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 140 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 55 номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 70 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 81 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 132 номерлы, 2024 елның 8 ноябрендәге 141 номерлы, 2025 елның 15 маендагы 164 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме «Баулы шәһәре» муниципаль

берәмлегендә Бюджет өлкәсе аерым оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи оклады күләменә туры китереп исәпләнә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 16 928 сум тәшкил итә.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча : (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

Баулы шәһәре мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров